**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Учаллинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д. 51 , село Учалле,
Азнакаевского муниципального района, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге**

**БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» октябрь 2020ел. №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 30 октябрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Совет урамы буенча 1 йорттан 45 йортка кадәр, Октябрь урамы буенча 1 йорттан 17 йортка кадәр, Комсомол урамы буенча 1 йорттан 8 йортка кадәр;

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 30 октябрендә 18 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Совет урамы буенча 46 йорттан 83 йортка кадәр, Яшьләр урамы буенча 1 йорттан 9 йортка кадәр, Тукай урамы буенча 1 йорттан 23 йортка кадәр;

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар Җыенының беренче этабын уздыру вакыты-2020 елның 30 октябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- Халык җыенының беренче этабын үткәрү урыны- Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт, Үчәлле авылы мәдәният йорты залы;

– гражданнар Җыенының икенче этабын уздыру вакыты-2020 елның 30 октябрендә 18.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр;

- Халык җыенының икенче этабын үткәрү урыны-Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт, Үчәлле авылы мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 20 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорты;

- сайлау хокукына ия булган Үчәлле торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Үчәлле торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган  түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар (тракторчы белән техниканы арендалау, сыешлыкны арендалау);

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»).

- Үчәлле авыл җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Җирле әһәмияткә ия булган Үчәлле автомобиль юлларын карап тоту: (Совет, Октябрь урамнары буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чаптыру буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре күрсәтү.);

- Үчәлле авылы зиратына контейнер мәйданчыклары урнаштыру, контейнерлар (бункер), киртәләр алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру ,нигез салу, коймалар урнаштыру);

- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару (күмү).

ӘЙЕ КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина